**ГЛАВА ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская, д.9 а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОМЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422625 Комлы Ковал авылы,
Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**2021 елның 22 ноябре** **8 номер**

**БОЕРЫК**

**Кадастр номерлары 24:090704:904, 16:24:090704:224 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 13 ноябрендәге 103 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кеше тормышы, хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларын үтәү максатларында, "Беренче төзелеш идарәсе" ҖЧҖ гаризасы нигезендә карар бирәм:

1. Кадастр номерлары 24:090704:904, 16:24:090704:224 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә;

2. Билгеләргә:

2.1 Үткәрү датасы һәм вакыты - 2021 елның 27 декабрендә 16.00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422625, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Комлы Ковал ав., Октябрь ур., 9А йорт.

2.3.Кадастр номерлары 24:090704:904, 16:24:090704:224 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашу хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкаларны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 422625, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Комлы Ковал, Октябрь ур., 9А йорт адресы буенча урнашкан Комлы Ковал авыл җирлегенең Башкарма комитетына тапшырырга.

2.4 Гавами тыңлауларда чыгыш хокукы белән катнашу өчен заявкалар бирү срогы- 2021 елның 25 декабренә кадәр.

3. Комлы Ковал авыл җирлеге территориясен планлаштыру проекты экспозициясе 2021 елның 26 декабреннән алып 2021 елның 27 декабренә кадәр Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча түбәндәге, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча: 422625, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Комлы Ковал ур., Октябрь ур., 9А. ачык булачак.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.С.Гыйлаҗетдинова**